КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 8 июль г.Казань № 567

«Татарстан Республикасының Газлаштыру, энергия саклаучы технологияләр һәм инженерлык челтәрләрен үстерү фонды» дәүләт казна учреждениесе исемен үзгәртү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Татарстан Республикасының Газлаштыру, энергия саклаучы технологияләр һәм инженерлык челтәрләрен үстерү фонды» дәүләт казна учреждениесе исемен үзгәртү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. «Татарстан Республикасының Газлаштыру, энергия саклаучы технологияләр һәм инженерлык челтәрләрен үстерү фонды» дәүләт казна учреждениесе исемен «Татарстан Республикасының Инженерлык челтәрләре баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе дип үзгәртергә.

3. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына һәм «Татарстан Республикасының Газлаштыру, энергия саклаучы технологияләр һәм инженерлык челтәрләрен үстерү фонды» дәүләт казна учреждениесенә:

15 көн эчендә «Татарстан Республикасының Газлаштыру, энергия саклаучы технологияләр һәм инженерлык челтәрләрен үстерү фонды» дәүләт казна учреждениесе уставына үзгәрешләр кертергә һәм аны яңа редакциядә закон белән билгеләнгән тәртиптә теркәүне тәэмин итәргә, законнар нигезендә башка кирәкле оештыру чараларын гамәлгә ашырырга;

10 көн эчендә, «Татарстан Республикасының Газлаштыру, энергия саклаучы технологияләр һәм инженерлык челтәрләрен үстерү фонды» дәүләт казна

учреждениесе уставына үзгәрешләр керткәннән соң, законнар белән билгеләнгән тәртиптә теркәлгән Устав күчермәсен Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына кертергә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин